
***Бергәләп өйрәник***



# ***Минем өй, минем бистә, минем республика***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

**(4-5 яшь)**

## Табышмаклар

* Көн-төн йөри,
Урыныннан китә алмый.
(Сәгать)
* Почмакта бер суык кыш,
Исеме аның... (суыткыч).
* Төймәсенә басу белән
Бәйли зәңгәр яулыгын.
Аш пешерә, чәй кайната —
Күрсәтә уңганлыгын.
(Газ плитәсе)
*Сөйләп бирә тел белән,
Сүзе китә юл белән,
Юлы агач башында. (Телефон)
* Үзе бер әрҗә,
Бөтен дөньяны
Күрсәтә. (Телевизор)
* Аяксыз, кулсыз
Өй саклый.
(Йозак)

## Туган илнең улы мин

Бабайның да
Улы мин,
Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый
Ярамый —
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

Роберт Миңнуллин

*Хәрәкәтле уен*

### *Тилгән һәм тавык*

Уен мәйданчыгының бер башында җиргә түгәрәк сызыла. Ул — «тилгән оясы». Уенда катнашучыларның берсе — «тилгән», икенчесе «тавык» итеп билгеләнә. Калган балалар «чебиләр» булалар. «Чебиләр» бер-берләренә тотынып, «тавык» артына те- зелеп басалар (алда торучы «чеби» «тавыкка» тотына). Уенны алып баручы «тилгән килә» дип сигнал бирә. «Тилгән» оясыннан чыга да колоннада соңгы булып басып торучы «чеби»не тотарга тырыша. «Тавык», «канатларын җәеп» (кулларын як-якка сузып), балаларын саклый. Ул «тилгән» кай- сы якка ташланса, шунда «тилгән»гә каршы чыга. Бу вакытта «чебиләр», бер-берләреннән аерылмыйча, «тавык» артыннан ияреп йөриләр, соңгы булып басып торучы «чеби»не тоттыр- маска тырышалар. Әгәр «тилгән» иң арттагы баланы тартып ала алса, ул аны үз оясына алып китә. Уен вакытында балалар чылбырны ычкындырмаска, «тавык»тан аерылмаска тырышалар